СОВЕТ ЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д.9, с. Нижние Яки
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422157

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Яңа ур., 9 нче йорт, Түбән Яке авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422157

тел.(факс): (85563) 2-94-38; e-mail: Yak.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение　　　　　　　　　　　　Карар

“13” апрель 2021 ел　　　　　　　　　№ 3-7

Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге Советы муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексына үзгәрешләр кертү турында

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы Федераль Закон, 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә», Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт хезмәткәрләренең хезмәттә үз-үзен тотышының гомуми принципларын раслау турында» 2002 елның 12 августындагы 885 номерлы Указы һәм Россия Федерациясе Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору советы Президиумының 2010 елның 23 декабрендәге 21 номерлы утырышы беркетмәсе нигезендә, муниципаль хезмәткәрләрнең этик нормаларын һәм хезмәт тәртибе кагыйдәләрен билгеләү, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең абруен, гражданнарның җирле үзидарә органнарына ышанычын ныгытуга ярдәм итү һәм муниципаль хезмәткәрләрнең бердәм тәртип нормаларын тәэмин итү максатларында Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге Советы

к а р а р к а б у л и т т е:

1. Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге Советының 18.04.2011ел, № 3-8 карары белән расланган Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексына (алга таба – Кодекс) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәр җирле үзидарә органында гамәлдә булган Россия Федерациясе законнары нигезендә кабул ителгән нормаларны һәм таләпләрне үтәү турында мәгълүматны эшкәртә һәм тапшыра.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми http://mamadysh.tatarstan.ru/ сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге башлыгы Р.К.Низаметдиновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Яке авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /Р.К. Низаметдинов/